**5 нче сыйныф**

**Татар әдәбиятыннан тест**

**Фоат Садрисвның «Тургай ни дип сайрый?» хикәясе**

**1. Хикәядә кайсы кошларның исемнәре телгә алына?**

а) тургай, сыерчык;

ә) тургай, сыерчык, торна, кыр казлары;

б) тургай, сыерчык, торна, кыр казлары, кара каргалар.

**2. Ни өчен тургайлар, яшәргә җайлы булган җылы якларны калдырып, безгә кайта?**

а) дөнья күрү өчен;

ә) туган җирләрен сагынып;

б) дусларын күрү өчен.

**3. Йомыркадан чыккач, тургайларның иң беренче күргән әйберләре нәрсә булган?**

а ) зәңгәр күк, ак болытлар, кояш;

ә) аллы-гөлле күбәләкләр;

б) иген камыллары, кара туфрак.

**4. Сабан тургайлары үзләренең дәртле җырларын кемгә багышлый?**

а) үз гомерләрен туган туфрак белән бәйләгән җир улларына һәм кызларына;

ә) туган якта яшәүче барлык кешеләргә;

б) яңа гына тәпи атлап китүче сабыйларга.

**5. Туган якларына кайта алмый калган кошларның фаҗигасе кайсы юлларда ачык чагыла?**

а) Кайбер кошлар туган җирен күрү бәхетен татый алмый.

ә) Картаеп яисә авырып оча алмаучылар безне яшьле күзләре белән озатып кала.

б) Сагыну сагышына түзә алмыйча, үләселәрен белә торып, һавага күтәрелгәннәр, туган якка кайта торган юлда җан биргәннәр.

**6. Туган җирнең кадерен, газизлеген сабан тургае балаларына ничек аңлата?**

а) Менә тиздән үсеп җитәрсең, шаулап-гөрләп укыган мәктәбеңнән аерылып, туган оең бусагасын атлап чыгып, ят җирләргә китәрсең.

ә) Шулчакта туган нигезеңне сагыну тойгысы керфекләреңә кайнар яшь бөртеге булып кунар.

б) Аһ, нинди татлы, нинди газиз ул туган җир! Аның салкыны да туңдырмый, аның каты җире дә йомшак мендәр кебек.

**Ачкыч**

1. Б
2. Ә
3. Б
4. А
5. Б
6. Б

**Бәяләү**

**5-6 балл – “5”ле**

**4 балл – “4”ле**

**3 балл – “3”ле**